**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

13.07.2024

№ 243

**Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында» 2011 елның 14 апрелендәге 172 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 28 апрелендәге 181 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 13 сентябрендәге 444 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге 537 номерлы, 2014 елның 5 августындагы 469 номерлы, 2014 елның 10 декабрендәге 697 номерлы, 2015 елның 15 августындагы 462 номерлы, 2016 елның 16 маендагы 294 номерлы, 2016 елның 22 декабрендәге 743 номерлы, 2017 елның 28 апрелендәге 258 номерлы, 2017 елның 7 июлендәге 427 номерлы, 2017 елның 11 декабрендәге 719 номерлы, 2022 елның 11 февралендәге 91 номерлы, 2022 елның 11 августындагы 262 номерлы боерыклары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 13 сентябрендәге 302 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләренең) коррупциягә каршы көрәшү максатларында «Коррупциягә каршы көрәшү турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча таләпләрне (алга таба – хезмәт тәртибенә куелган

таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләр) үтәүне, вазыйфалар башкаруын тәэмин итүдә;»;

12 пунктка түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасы өстәргә:

«е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләрне үтәүгә комачаулык итүче ул йогынты ясый алмый торган шартларның барлыкка килүе турында хәбәрнамәсе.»;

$13^4$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$13^4$. Әлеге Нигезләмәнең 12 пункты «б» пунктчасы бишенче абзацында һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләр Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты яисә Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының коррупциячел яисә башка төрле хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карап тикшерелә, ул хәбәрнамәләрне карап тикшерү йомгаклары буенча нигезле бәяләмәләр әзерли.»;

$13^5$ пунктта «12 пунктның «д» пунктчасында» сүзләрен «12 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

$13^6$ пунктта:

«а» пунктчасында «12 пунктның «д» пунктчасында» сүзләрен «12 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 12 пункты «б» пунктчасы икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле йомгак, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 20, $21^3$, $21^4$, $22^1$ пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.»;

$14^2$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$14^2$. Әлеге Нигезләмәнең 12 пункты «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карап тикшерелә.»;

15 пунктта «12 пунктның «б» пунктчасы» сүзләрен «12 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

$15^1$ пунктның «а» пунктчасында «12 пунктның «б» пунктчасы» сүзләрен «12 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $21^4$ пункт өстәргә:

«$21^4$. Әлеге Нигезләмәнең 12 пункты «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре йогынты ясый алмый торган шартларның барлыкка килүе һәм аның хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләрне үти алмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын тану;

б) дәүләт хезмәткәре йогынты ясый алмый торган шартларның барлыкка килүе һәм аның хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләрне үти алмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын тану.»;

22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Әлеге Нигезләмәнең 12 пункты «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карап тикшерү йомгаклары буенча һәм аны кабул итүгә тиешле нигезләр булганда, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 18–$21^{4}$ һәм $22^{1}$ пунктларында каралган карарны түгел, ә башка карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итү өчен нигезләр һәм сәбәпләр Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелергә тиеш.».

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**